ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап турында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан милли тикшеренү технология университетының Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерүгә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә, сәнәгать тармагы өчен кадрларның квалификациясен арттыруда һәм аларны яңадан әзерләүдә актив катнашуга, нефть-газ химиясе тармагының эре предприятиеләре һәм цифрлы индустрия компанияләре белән партнерлыкта «Промхимтех» алдынгы инженерлык мәктәбендә укытуның яңа моделен гамәлгә кертүгә, талантлы балалар өчен химияне тирәнтен өйрәнү интернат лицее һәм Казан технология колледжы базасында өзлексез укыту концепциясен үстерүгә керткән өлешен, химия технологияләре өлкәсендә фәнни тикшеренүләрне һәм заманча эшләнмәләрне арттыруда һәм гамәлгә ашыруда әйдәп баручы булуын билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны хупларга.

2. «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында университетны үстерү программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 162-VII ДС